РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

ЯҢА ЕЛГА КҮЧТӘНӘЧ



РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

ЯҢА ЕЛГА КҮЧТӘНӘЧ

ХИКӘЯЛӘР

КАЗАН · ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ · 1979

С(Тат)2
М98

ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВ
рәсемнәре

Урта яшьтәге мәктәп балаларына

М $\frac{70803-178}{М132(03)-79}$ 164—79

© Татарстан китап нәшрияты, 1979.

Яңа елга күчтәнәч

Шамил белән Камил — күршеләр. Яңа ел бәйрәменә күчтәнәч булсын әле дип киттеләр болар балыкка. Шамил бабасының киез итеген киде, Камил — әбисе итеген.

Тиштеләр болар бәке. Салдылар кармакларын. Көттеләр-көттеләр — балык эләкмәде. Болар тагы көттеләр. Эләгер дип өмет иттеләр.

— Шаулашмыйк,— диде Шамил.

— Шулай шул,— диде Камил,— алайса балык кача.

— Селкенмичә утырсак, бер эләгер ичмаса.

Малайлар кармакларын тагын салдылар, салдылар да бүкән кебек катып калдылар. Көттеләр-көттеләр малайлар — балык капмады.

— Шаулашыйк,— диде Шамил.

— Шулай шул,— диде Камил,— безнең тавышка килсеннәр. Ике зурысы капсын, калганнары качсын.

Малайлар кармакларын яңадан салдылар, кычкырып сөйләшеп тә алдылар.

Шамил алды кармагын — ул буш чыкты. Камил алды кармагын — аның эше икеләтә «шәбрәк» булып чыкты, балыгы да юк, кармагы да.

— Мин киттем,— диде Камил, сикереп торды. Аннан лып итеп әрҗәсенә яңадан утырды.

— Мин дә,— диде Шамил, сикереп торды. Ул да лып итеп әрҗәсенә утырды.

— Капты,— диде Шамил,— капты, бабай итеге бозга катты!

— Минеке дә капкан,— диде Камил,— әби итеге бозга каткан.

Озак маташтылар малайлар. Итекләрен йолыктылар-тарттылар, боз өстендә дүрт олтан калдырып, арыпталып өйләренә кайттылар.

Куркак Гаяз

Бу кушаматны беренче булып кем кушканын, мөгаен, үзе дә хәтерләмидер Гаяз. Алай исе дә китми аның, куркак булгач, нишләсен, ризалашырга туры киләдер инде. Шулай да минем һич кенә дә үчеклисем килми Гаязны, күңелемнән генә аның дусты да булып йөрим әле. Ата каздан бер Гаяз гына шүрли диярсең... Канатларын җәеп, ыссылдап өстеңә ташланса, качмый нишлисең ди инде. Гаязның да артык сыйрагы юк ла, шуны белә торып, куркак диләр...

Көннәрдән беркөнне бергәләшеп урманга барырга булдык.

— Җыелышып беттек бугай, малайлар,— ди Наил.

— Юк,— мин әйтәм,— Гаяз киләсе бар әле.

— Кайсы Гаяз?

— Куркак Гаяз...

Малайлар көлешеп алдылар. Ул арада Гаяз үзе дә килеп җитте. Күп сөйләшеп тормый, турыдан гына урманга таба җилдердек.

Урман урман инде, бер менгәч, кармак сабы белән генә чикләнеп калып буламыни?! Уйнаша-уйнаша әллә кайларга барып чыктык, шундый иркен, тыныч урманны ташлап кире кайтасы киләме соң... Төрлебез төрле якка сибелеп, җиләклек эзли башладык.

Кинәт, бөтен урманны сискәндереп, якында гына чырылдавык тавыш яңгырады. Наил тавышы.

— Җыла-ан! Җылан!..

Бер мизгелгә катып калган аякларны көч-хәл белән урыннарыннан кузгатып, куак артларына поса-поса, шул якка атладык. Куркыныч булса да күрәсе килә иде шул еланны.

Чү, әллә куркуыннан җиңеләя башлады инде, нишләве бу Гаязның? Бөтенебездән алда еланга таба туптуры бара бит.

— Әй, җүләрләр,— ди үзе,— җыланмыни, тузбаш ич бу!

Малайлар, бертавыштан «ах» итеп, авызларын ачтылар. Гаяз еланның янына ук барып җитте.. Кулы бе-

лән сыртыннан сыйпый түгелме соң?.. Ә елан, Гаязга нидер әйтергә теләгәндәй, боргалана-боргалана башын күтәрә башлады.

Безнең күзләр маңгайга менгән, авыз ачылмый да, ябылмый да. Бары тик Наил генә, йөрәге җитеп:

— Гаяз! Куркак Гаяз! Нишлисең, чага бит! — дип кычкырып җибәрде.

Зәңгәр бантик

Янымда гына утырган Фәйрүзәнең бантигына каныккан малайларга нигәдер ачуым килә башлады. Кайчак тәнәфес вакытында кинәт кенә класста тавыш куба. Ни булды дисәң, Фәйрүзә тасмасын тартучы тиктормасны куалап киткән була. Кара чәчләреннән сузылып төшкән зәңгәр тасма гына күренеп кала... Ашыга-ашыга яңадан класска килеп кергәндә, түгәрәк йөзе тагын да алсулана төшкән була, үзе бераз ачуланган сыман, шулай да күзләре һаман уйнап тора. Бит урталары да яшерен елмаюның серен сөйли кебек. Ул шулай җиңел генә парта артына килеп утыра да, иң өсләренә чем-кара толымнарын салып, чәчләрен бантикларга керешә. Толымына зәңгәр күбәләк кунганмыни! Ул үзе дә күбәләк күк, менә-менә очып китәргә торган сыман...

Ә малайлар һаман ачуны китерүдән туктамыйлар. «Күбәләк очыртабыз» дип, шул бантиктан тарту кызык шул аларга. Малайларга ачуланып, Фәйрүзәгә сүз әйтергә оялып йөрүнең чиге булырга тиештер бит инде...

Фәйрүзәнең су буена бәбкә көтәргә төшеп киткәнен бура артына качып сагалап тордым да, кулга кармак сабы тотып, мин дә балыкка киттем. Яшькелт-сары каз бәбкәләре йөгерешеп төшкән уңайга су өстеннән йөзеп тә киттеләр.

— Фәйрүзә!

— Ә-ә-ә, исәнме, балыкчы! Ни тотмакчы буласың монда?

— Балык.

— Ә-ә-ә, балыкмыни?..

Кармакны инешнең теге ягына ук салдым да күз кырыем белән генә күзәтә башладым. Фәйрүзә яшел чирәм өстенә утырган да аяклары белән су чупылдата, бәбкәләре белән уйный. Үзе бераз иелә төшкән, әйтерсең лә су өстендәге шәүләсен күреп куана. Зәңгәр бантиклары, каз бәбкәләре сыман менә-менә суга сикереп төшәрләр дә, вак-вак дулкыннар чыгарып йөзеп китәрләр кебек...

— Әй!

— Нәрсә?!

— Йокыңнан уян, балык эләккән ич!

Фәйрүзә эндәшүе икән.

Бөтен көчем белән тарткан идем, кыйгылдап кычкырган каз тавышыннан сискәнеп, кармак сабын чүт кенә суга төшереп җибәрмәдем. Балык түгел, Фәйрүзәләрнең ата казы эләккән икән. Кармакны казы-ние белән яр буена тарта башладым. Хәзер казны кармактан ычкындырырга кирәк инде. Үрелүем булды, ата каз канатларын җилпеп колак төбендә генә ысылдап җибәрде. Ә үзем нинди тавыш чыгарганмындыр, хәтерләмим, кармак сабын калдырып өйгә таба элдердем.

Икенче көнне дәрескә бармаска булдым. Өйдә әби генә калган иде. Авырыйм, дидем. Инде ышандырып кына бетергән идем, ишектән, кулына сумкасын тотып, Фәйрүзә килеп керде.

— Синең кармагыңны китердем,— ди.

Нишләргә белмичә мендәр артына постым.

— Әйдә, дәрескә соңга каласың бит, тизрәк бул, көтеп торам,— ди Фәйрүзә.

Шул сүзләрне ишетүгә, барын да онытканмын, ахры. Ни арада «терелеп», әзерләнеп, ишектән чыгып йөгергәнемне сизми дә калдым. Мәктәпкә җиткәнче, Фәйрүзә, зәңгәр бантиклы чәчләрен җилфердәтеп, алдан барды. Мин — аның артыннан.

Урак өсте иде

Урак өсте иде... Әтиләрнең өйгә кайтып кергәнен дә хәтерләмим. Көн дими, төн дими, басуда ашлык суктыралар. Кояш төшкә авышкач ук, бер кулга кар базыннан менгән салкын катык, икенчесенә кайнар аш салынган савыт тотып, көндәгечә, әтиләр эшли торган басуга таба юнәлдем. Ындыр артыннан ерак та китмәдем, арттан машина белән выжлап куып та җиттеләр...

Тагы берничә минуттан, комбайн кырыендагы салам өеменә ятып, әти белән Сәләхи абый борчак ашы сыпырталар иде инде. Ипиләрен капкан арада миңа да ымлап алалар, күңелне күтәрәләр, янәсе. Комбайн гөрелтесеннән алар үзләре дә ни әйткәннәрен ишетми торгандыр югыйсә.

Ул арада Сәләхи абый туеп та өлгерде, ахры, яткан җиреннән сикереп торып кулын сыпыргалап алды да: «Ну, яратам да соң борчак ашын...» — дип, мине салам чүмәләсе өстенә ыргытты. Чүмәлә өстендә мәтәлчек атып аның икенче ягына шуып төштем. Сәләхи абый комбайн тирәсендә маташа иде инде. Мине үзе янына чакырып кул изәде: «Киттек». Әти беркавым ял итеп алганда, без көн саен шулай аның белән бер әйләнеп киләбез. Әлегә ярдәмче булып кына эшләсә дә, менә дигән комбайнчы бит ул Сәләхи абый. «Кулы эшкә ятып кына тора, белмәгәне юк!» — ди аның турында әти. «СК-4» не үкертеп, бодай басуына кереп киттек. Комбайн артыннан рәт-рәт булып салам өемнәре утырып кала. Мотор гөрелтесенә кушылып салмак кына бункерга аккан бодай тавышы ишетелеп тора.

Көтмәгәндә комбайн шып туктап калды. Сызгырынып барган җиремнән әздән генә очып төшмәдем. Сәләхи абыйның шаяруы түгелдер, чынлап та нидер булган иде, ахры. Зур бияләйләрен минем аяк астына тотып ыргытты да Сәләхи абый җиргә сикерде. Комбайн тирәсендә ниндидер шомлы хәл булуын хәбәр итеп, арлы-бирле кошлар очып йөри. Комбайн гөрелтесенә

кушылып, аларның үзәк өзгеч тавышы ишетелә иде... Җамыл өстеннән сак кына атлап, мин дә Сәләхи абый янына килдем. Шатыр-шотыр эшләп торган тимер пычаклар каршында гына коры үләннәрдән үреп ясалган нәфис кош оясы, ә ояда өч кош баласы. Үзләре нәни канатлары белән кагынган булалар, зәңгәр күккә табан омтылулары, күрәсең. Берәве нәни канатларына таянып күтәрелде дә күз алдында оясыннан камыл арасына егылып төште. Бер мизгелгә тынып торган кошларның чыр-чуы баш өстендә генә яңадан яңгырый башлады. Нишләтәбез инде боларны дигәндәй, Сәләхи абый белән бер-беребезгә карашып алдык. Читкәрәк алып куйсак, бу басуны берничә көннән сукалаячаклар...

— Җитер әле монда,— дип, Сәләхи абый башымдагы фуражканы алгач, күңелгә җылы кереп китте. Ул түбәтәй кадәр оялары белән бергә кош балаларын сак кына фуражкага салып миңа сузды.

Комбайнның барлык тәгәрмәчләре һәм чылбырлары яңадан хәрәкәткә килде. Башаклар, кошчыклар исән калды бит дигәндәй, нидер пышылдашып, Сәләхи абый белән безнең каршыда баш ия башладылар. Шул рәвешчә, берни сөйләшмичә басуның урман куенына елышкан почмагына да килеп җиткәнбез. Кош балаларының сары нәфис томшыкларына, йомшак нәни канатларына сокланып бара идем, Сәләхи абый, тормозга баса төшеп: «Әнә басу читендәге кызыл миләшне күрәсеңме?.. Шуның ботаклары арасына урнаштыр үзләрен»,— дип, комбайн гөрелтесеннән уздырырга теләгәндәй, миңа эндәште.

— Ничек инде алай, алар бит ачтан үләчәк...

Җиңелчә генә колактан тартып, Сәләхи абый елмаеп куйды һәм кулы белән кояшлы күккә таба күрсәтте. Анда зәңгәр киңлекне иңләп, безнең өстән әлеге кошлар оча иде. Комбайн тагын кузгалып китте, ә мин фуражкамны тотып ялгыз миләшкә таба йөгердем.

Актүшем

I

— Болында печән әйбәт быел,— ди эти. Берәр сәгать чамасы чапкандыр, покосларда дөнья кадәр печән ятып калды. Ул арада мин дә, калкурак урыннарда үскән куаклыкка кереп, туйганчы кара җиләк һәм бөрлегән ашадым. Аннан, күләгәгә сузылып ятып, чыпчык кузгалагы белән ачы кукыдан авыз иттем. Күбәләкләр куып йөргәч, фуражка тутырып, этигә дә җиләк җыеп килдем.

Эти инде йөкне төяп бетерә язган иде, «Кая йөрисең, малай актыгы?» дип кенә куйды да артык орышып тормады.

— Юк, эти, үзем менәм,— дип карасам да, тыңламыйча, зур куллары белән аркадан эләктереп йөк өстенә тотып атты үземне.

— Ныгытып тапта, ишелерлек булмасын! — Үзе һаман төявендә булды.

Менә ичмаса бу йөк, дугадан да биек!

Атны эти тотып кайтты. Ә мин печән йөгенең уйсулана төшкән уртасына сузылып ятып дуга өстеннән үзебезнең авыл ягына, Шәвәли бабайларның мунчасы артына батып барган кояшның алсу нурларына карашымны төбәп, җиләк яфраклары чәйни-чәйни, матур уйлар дөньясына чумдым.

Әкренләп кайта торгач инеш буена да җиттек. Эти, аркалыкны бушатып, сызгыра-сызгыра малкайга су эчертә башлады. Мин дә, йөк өстеннән төшеп, бераз сикергәләп җылынып алыйм дидем. Инде кичке салкын төшеп килә иде. Тирә-як тын. Вак ташлар арасыннан аккан инешнең серле челтерәве шушы тынлыкка сихри бер моң өсти кебек. Офык артыннан чыгып килгән тулган ай нурлары, балык тәңкәләредәй ялтырашып, су өстендә уйный. Көтмәгәндә ат пошкырып куйды...

— Әләй, эти, әнә тегеннән әллә нәрсәнең әллә нинди тавышы ишетелә...

Ничек курыкмый бу эти, тавыш ишетелгән якка китте дә барды. Мин аңа ияредем.

Әти кечкенә генә чокыр янына туктады. Һи, эт икән ич... Кулымдагы ташны бер читкә ыргытып, әти янына йөгереп килдем. Мине күргәч, эт тагы бер шыңшып куйды.

— Әти, үзебез белән алыйк әле, бөтен малайларның да эте бар, минем генә...

Әти каршы килмәде, этне минем кочакка салды да:

— Алып кайт, аягы җәрәхәтләнгән булса кирәк,— дип, атка таба китте.

Кара инде, дер-дер килә, үзе ябык, гәүдәгә дә зур түгел икән. Кичке салкын онытылды. Табылдык эт белән сөйләшә-сөйләшә өйгә кайтып җиткәнне сизми дә калдым.

II

Актүшемнең аягындагы яра берничә көндә төзәлеп бетте. (Ул чем-кара эт булып, түшендә уч төбе кадәр генә ак урыны бар иде, шуңа мин аны «Актүш» дип атадым.) Инде ияләшеп тә килә үземә, ишектән чыгуыма койрыгын болгый-болгый каршы ала. Ул гына да түгел, яныма ук килеп түшкә сикерә дә соры күзләре белән уйчан гына карап тора. Бераз карап торгач, берни аңламыйм дигәндәй, үпкәләгән сыман читкә китеп бара.

Гәүдәгә зур булмаса да, киң күкрәкле, таза аяклы эт ул үзе. Һич тик тора белмәс, баскыч төбендә утырып аны күзәтүдән дә кызыклырак ни бар икән! Әле тавыклар белән уйнамакчы була, ә тегеләре шаяруның ни икәнлеген белмиләр, «кыт-кытыйк» килешеп, капка астыннан чыгып качалар. Актүш беренче көндә үк инде ата каз белән дуслыкны өзгән иде. Хәер, үземнең дә бар сөймәгәнем шул ата каз, бөтен белгәне боттан тешләү генә ич аның! Шулай анда сугылып, монда сугылып йөри торгач, барысына үпкәләгән кыяфәт белән, мин ясап биргән оя күләгәсенә барып ята. Хәйләкәр дә соң, башын яшереп йоклаган булып кына ята да: һап! — чебеннәр безелди дә алмый кала.

Әледән-әле Актүшемне ияртеп ындыр артына чыгып

чабам. Бергә булу, бергә уйнау рәхәт, күңелле. Әни пешергән коймаклар белән сыйлыйм үзен. Шулкадәр яратыр икән!.. Ашап бетермәс борын тагы кесәгә үрелә, бармакларны ялаган була. Хәйләкәрнең дә хәйләкәре инде үзе, керфек тә какмый күзләрен тутырып карап торганда, их дигәндәй, бер көрсенеп ала, койрыгын селкә — тагын коймак сорый. Кесә бушап калган, ә ул мине саранлыкта гаепли кебек...

— Ай-яй-яй,— янәсе, синнән көтмәгән идем.

Ул үпкәләгән булып читкә киткән арада, сиздерми генә кукуруз басуына кереп качам. Ни арада өлгерә диген, шунда ук куып җитеп чалбарга килепябыша. Боттан тешләгән була, балактан тарта, үзе аз гына да авырттырмый. Муеныннан кысып кочаклыйм да сузылып җиргә яткан килеш бер-беребезгә карашып торабыз. Их, беләсе иде, нәрсә уйлый икән ул? Шундый акыллы итеп уйга чумып ята, андый этне сезнең күргәнегез дә юктыр әле.

Шулай эндәшми генә озак-озак утыра торган идек. Якын дустым булуга куанып бетә алмый идем мин. Матур җәй көннәренең бер-бер артлы үтүе сизелми дә кала иде. Урманга барганда да, балыкка төшкәндә дә Актүшне үземә ияртәм, аның белән бергә булу күңелле иде, кызык иде.

Көннәрдән беркөнне үзебезнең урам малайлары белән каенлыкка җиләк җыярга киттек. Көн һәрвакыттагыча матур, кояшлы. Рәт-рәт булып тезелеп киткән каеннарның тирә-ягында хуш исле үләннәр, төрле-төрле төстәге чәчәкләр арасында алсуланып пешкән каен җиләкләре җемелдәшә. Берсеннән-берсе татлырак, кызылрак җиләкләрне җыйган саен җыясы килә. Актүш тә бездән калмый, җиләклекнең шәплегенә соклангандай, әле бер, әле икенче якка йөгерә-йөгерә безнең куанычны уртаклашып йөри. Җиләкләр, чәчәкләр хуш исе аңа да ошап китте, ахры...

Ачыга төшкәч, матур бер аланлыкта туктап, бодай күмәченә хуш исле каен җиләге ягып ашарга утырдык. Ә монысы Актүш өлеше...

— Актүш, Актүш, дим! Актүш!..

Никадәр генә кычкырсам да, дускаемның куаклыклар арасыннан атылып килеп чыгуын никадәр генә

көтсәм дә, җавап бирүче булмады. Акрын гына искән җилдә җанланып алган яфраклар кебек, бөтен тән эсселе-суыклы булып, сискәнеп, калтыранып куйдым. Утырган җирдән сикереп тордым, башта әле генә Ак-түш уйнап йөргән куаклыклар янына, аннан якындагы юл буена йөгердем, ә Актүш...

Кечкенә сеңелемнең су ташый торган чиләгенә җыелган кып-кызыл җиләкләр юлдагы тузан өстенә төшеп чәчелделәр.

Борылышка җитеп килгән атлы кешене куып тотмак булып, фуражкамны болгый-болгый озак йөгердем. Тавышымны ишетепме, Актүшем беразга тукталып миңа таба карап торды, ә аннары арба артыннан күтәрелгән тузан эченә кереп югалды.

III

— Улым, артык мавыгасың, эт барыбер үзенең элекке хуҗасын табар,— дип кисәтә иде әти.

Дустымның шулай җиңел генә ташлап китүенә ышанасым килми иде, үз күзләрем белән озатып калуга да карамастан, әле мин аны озак көттем, һәр көн иртән, ишек алдына чыгуга, койрыгын болгый-болгый капка астыннан Актүшем килеп керер кебек иде.

Зәлифә

Печән чүмәләсе төбендә утырабыз... Фаяз, пәке белән кырып алынган шоп-шома башын сузып, миңа сыена төште:

— Җә-җә... Ялындырып торган булма инде.

Бер читкә карап, шыпырт кына әйттем дә салдым. Ни дисәң дә, дус бит.

— Ярата башладым бит әле, малай...

— Нәрсәне? — Фаяз җилкәмә кулын салып, мине үзенә табарак тартып куйды.— Нәрсәне ярата башладың, әйт инде!

Әллә, аңламаганга салышып, мине тагы да оялтырга җыенуы инде, әллә чынлап та аңламады.

— Җә инде, җә! Әйтә башлагач, әйтеп бетер инде!

Минем телсез калуыма гаҗәпләнгән сыман, ул үзе үк җавап эзли башлады:

— Кыяр белән помидорны син электән яратасың. Алма да түгел. Кишер белән үзегезнең бакча тулган... Нәрсә булыр икән?

Андый чүп-чар гына булса, яшереп торыр идеммени! Шулай да түзмәдем:

— Зәлифәне...— дип әйттем дә салдым.

Фаязның күзләре очкынланып китте.

— Кайсы Зәлифәне? Безнең класста андый кыз юк ич.

Түбән оч әбиләрнең күршесе Саттар абыйлар кызы ул Зәлифә. Бу исем безнең авылда артык күп очрый торганнардан түгел иде, шуңадыр, Фаяз үзе үк эзләп тапты.

— Ә-ә, теге түбән оч Зәлифәме?

— Син аны каян беләсең? — дип сорап куйдым, үзем дә сизмәстән.

Миңа безнең авылда Зәлифә исемле кызның булуы турында башка һичкем белмидер кебек тоела иде. Фаязны, күрәсең, башка берни дә кызыксындырмады. Ә мин әле Зәлифәнең чем-кара толымнары, нәфис зәңгәр чиләкләре турында да сөйләгән булыр идем. Ник тынып калдың дигәндәй, Фаязга карап куйдым. Үзе әйбәт кенә малай булса да, кызып китә торган гадәте бар аның. Дустымның иреннәре кыймылдый башлауга ук сизеп алдым, ул нидер әйтергә ниятләнеп күңелдән генә җөмлә төзи иде.

— Беркөнне көтү каршына төшкәндә күрдем мин аны,— дип башлады сүзен Фаяз тыныч кына,— теге яшенле яңгыр яуган көнне. Сыерлары бик тыңлаусыз икән. Һич кенә тыңламый бит Зәлифәне, кукуруз басуына таба кача. Чыбыркы белән бер-икене сыздырткач кына борылды.— Фаязның күңеле һаман күтәрелә бара иде.— Ә Зәлифә: «Чыбыркың бик шәп икән»,— дигән була.

— Ә син ни дидең?

— Без аны Сафа абый малае белән бергә үрдек, дидем.

— Ул нәрсә ди?

— Ә-ә-ә,— ди.

Эчкә җылы кереп китте, болай булгач, Зәлифә дә мине белә икән.

Көтмәгәндә Фаяз чәпелдәтеп иңбашыма сукты һәм:

— Зәлифәне мин дә ошата башладым бугай, малай! — дип кычкырып җибәрде.

Ошатмаслык та түгел, әйбәт кыз шул ул Зәлифә.

Озак сөйләшеп тормый гына, чүмәлә астыннан чыгып түбән оч әбиләргә таба чаптык.

...Әбиләрнең бәрәңге бакчасы. Зәлифәне күзәтү урыным шул инде. Ул һәр көн кичкә таба теге зәңгәр чиләкләре белән инештән су ташып кыяр түтәлләренә су сибә яки, кулына яшел бизәкле савыт тотып, чия җыя торган иде. Зәлифәләрнең авылда дан тоткан чия бакчалары булуы турында да әйтмәдем бугай әле.

Әби соңгы вакытта мине мактап бетерә алмый иде. Капканы ачуга ук ул бүген дә:

— Улым булышырга килгән икән. Һай рәхмәт, һай рәхмәт! — дип сөйләнде.

— Рәхмәте соңыннан булыр, әби... Помидорларны бәйлисе бар.

— Бер бәйләгән идең бит инде, улым.

— Юк, әби, ул таяклар кыскарган, хәзер яңадан бәйләргә кирәк.

— Без мәктәп бакчасында озын таяклар куеп бәйләдек, име! — дип Фаяз да өстәп куйгач, әби карышып тормады.

— Мин ни, ял итсәгез дип кенә әйтүем иде. Әйдәгез, башта катык ашап чыгыгыз алай булгач.

— Юк, әби, ашыйсы килми безнең,— дип, тизрәк бакчага юнәлдек.

Шыгырдап ябылган бакча капкасы артыннан әбинең: «Һай рәхмәт! Һай рәхмәт!»— дигән тавышы гына ишетелеп калды.

Зәлифә бакчада иде. Ул әлеге яшел бизәкле савытына чия җыеп йөри. Фаяз, минем яныма ук килеп, пышылдарга кереште:

— Вәт малай, чия дисәң дә чия ичмасам, авыз итеп карыйсы иде...

Әгәр бакча Зәлифәләрнеке булмаса, без, мөгаен, киртә аша сыгылып төшкән чияләрне өзми түзә алмас идек.

Кҗзне күрше бакчадан алмый гына помидор бәйләгән булабыз. Мавыгып китеп, бәрәңге сабакларын да бәйли башлаганбыз... Зәлифә чия җыя. Әбиләр бакчасында эшләүдән дә рәхәтрәк тагын ни бар икән?!

— Әйдә куркытабыз үзен,— ди Фаяз.

— Ә курыкса нишләрбез?..

Дустым иңнәрен җыерып алды. Фаязның да Зәлифәне куркытырга ярамаганлыкны аңлавына шатланып куйдым.

Уйламаганда чия куаклары арасыннан чая тавыш ишетелде:

— Әй, малайлар-калайлар, нишлисез анда?

— Зәлифә тавышы бит бу! — диде Фаяз, зур ачыш ясагандай.

Бу тавышны беренче ишетүем иде. Уйлап-нитеп тормый гына:

— Әби помидор бәйләргә кушканые,— дип әйтеп ташладым, үзем уңайсызланып Фаязга карап куйдым.

Зәлифә, тагын берничә чия өзеп яшел бизәкле савытына салгач, безгә таба күз сирпеп:

— Чия ашыйсыгыз киләме? Килсә, керегез! — диде.

Килүен килә дә, нишлик икән соң дигәндәй, бер-беребезгә карашып алдык.

— Әниләрең кайтып керсә?

— Алар бүген соң гына кайталар.

Монысы да мәгълүм булгач, киртә арасыннан шыпырт кына бер-бер артлы Зәлифәләр бакчасына кереп киттек.

Фаяз миннән кыюрак булып чыкты. Ул керүгә үк, Зәлифәнең буе җитми калган бер ботакны иеп, чия ашый башлады.

— Чиягез шәп икән...
— Шәп шул.
Ул арада Фаяз Зәлифә янына барып та җиткән иде инде.
— Зәлифә, әнә теге ботакны иеп биримме?
— Һи, синең анда буең да җитми бит.
— Минемме?..— Ике уйлап тормыйча Фаязның сикерүе булды, Зәлифә изелеп пешкән чия тармаклары арасында күмелеп калды.
Моңа кадәр минем бакчада икәнлегемне белмәгән диярсең, Зәлифә бераздан гына:
— Син кем буласың? — дип сорап куйды.
— Минме, мин Сафа абый малае...
— Мин Саттар абый белән Мәрфуга түти кызы,— дип, авызына бер чия капты да Зәлифә шундый матур итеп көлеп җибәрде.
Менә таныштыгыз да дигәндәй, Фаяз, чия яфраклары арасыннан елмаюлы караш ташлап, күз кысып куйды.
Чын дуслык әнә шулай да башлана икән ул...

Хоккей, без һәм Гаптери

Көтмәгәндә хоккей җене кагылды үзебезгә. Газеталарда язалар, кичләр буе радиодан сөйлиләр — шаушу киләләр. Гаптериләрнең телевизоры да гел хоккей гына күрсәтә икән. Телевизор каршында шәһәрдән кайткан абыйларына кушылып ул да: «Шайба! Шайба!» — дип кычкыра башлаган ди. Дөрес булса, әниләре Хөршидәтти, күршеләргә кереп:
— Улларым шаша бугай, кичләр буе шул «хөки»ләре белән кычкырышып утыралар,— дип әйтеп әйткән ди.
Нигә безгә дә уйнап карамаска шул хоккейны?
— И-и-и,— ди Гаптери,— аның өчен капкалар, кәшәкәләр, каскалар һәм тагы әллә нәмәрсәләр кирәк шул,— ди.

Малайлар карашларын Барыйга төбәп тын калдылар. Хәер, әле Барыйның кем икәнен дә белмисездер сез. Безнең урамда иң көчле малай ул.

— Уйныйбыз аны,— диде Барый.

Барый әйттеме — бетте инде, болай булгач уйныйбыз да уйныйбыз.

Ял көненә инде барысы да әзер иде. Буа өстеннән карын көрәп, бәкедән су ташып, менә дигән мәйдан ясадык.

— Телевизордагы кебек үк булмаса да, шәп булды бу,— ди Гаптери.

Зур-зур ике тартма табып капка иттек. Берничәбез куаклыкка төшеп кәшәкәләр кисте, ә алка өчен консерв банкаларыннан да шәпне тапмадык.

«О-о!» — диештеләр түбән оч малайлары. Үзебезгә каршы уйнарга дип чакырган идек аларны.

Безнең капкага бәләкәй Вакыйф басты, әтисенең зур итекләрен, бияләйләрен кигәч, гел үсеп киткәндәй булды тагы үзе.

Гаптери судья булды.

Түбән очлар: «Судья сезнең урамнан булмасын!»— дип килешми карасалар да, тиз тындылар. Гаптерине үпкәләтсәң — бөтенләй судьясыз калуың бар.

Судья гильзасын сызгыртуга, уен башланып китте. Һи, Барый барында безнекеләр бирешәме соң! Бишәүләп түбән очлар тартмасын атакалый башладык: шалтыр да шолтыр. Капкачыларын гына менә һич кенә алдап булмый, үзе юан, үзе елгыр — гомере буе тартма капканы саклаган диярсең.

Имән аудардылармы дисәм, Барыйны сузып салганнар икән.

— Бу силовой прием була! — ди Гаптери. Барыйның сүзләренә колак та салмый, Гаптери һаман үзенекен итә:— Хоккей — егетләр уены, болар гына пүчтәк әле ул! — ди. Эшләрнең катлауланып китүе дә бар иде. Арт яклап кына Барыйның колагына: — Судья белән бәхәсләшергә ярамый! — дип пышылдадым.

Уен яңадан кызып китте, кәшәкә белән суккан саен банка яньчелә-яньчелә йомрылана, тагы да кечерәя бара иде. Ә теге капкачыны һич алдап булмый: таяк

белән дә төрткәләп карадык, бер-ике еккалап та алдык. Нишлисең бит, аркылыга да, буйга да тартманы каплап кына куя! Ул гына җитмәгән, Гаптери әле беребезне, әле икенчебезне, ике минутка дип, уеннан куа башлады. «Бәхәсләшсәң, уеннан бөтенләй куам!» — дип янап тора, каян шулкадәр белә диген, әллә шыттыра да инде.

Ул да түгел, Барый капкачыны сузып салган, Гаптеричә әйтсәк: «силовой прием» була инде бу. Шул чак мин сугып җибәргән банка шалтырап тартмага барып кермәсенме! Малайлар мине урап алып кочаклый башладылар. «Булдырдың!» — диләр. Күңелләр күтәрелеп китте.

— Юк, дөрес түгел! Капкачыга көч куллану ярамый,— диде Гаптери.

Малайлар урап алып, җикеренә-төрткәли башлагач, судья гел кечерәеп калгандай булды.

Зур бияләйләрен йомарлаган бәләкәй Вакыйфка кадәр: «Эләгерсең әле, Гаптерүш! — дип җибәрә.— Шул түбән оч малайларың белән генә уйнарсың инде моннан соң, яме, Гаптерүш!» — ди.

Яңадан уйный гына башлаган идек, Гаптери: «Вакыт бетте!» — диде.

Ярый, ничья булса булыр дидек тә, Гаптерине тирги-тирги, үзебезнең урамга таба тыкрыктан менеп киттек. Бераз арылган да бугай, бозга мәтәлгән урыннар да авырткалый башлады, ләкин барыбер аяклар гадәттәгедән тизрәк атлый, күңелләр көр иде...

Тау башына менеп җиткәч артыма борылып карадым — анда үзебез ясаган хоккей кыры җәелеп ята. Инде шау-шу тынган, боз өстендә мыжлап торган малайлардан бары берәү — Гаптери генә калган. Ул тартмаларны кеше күрми торган җиргә, кар астынарак яшереп маташа. Ә бераздан кулына себерке алып ашыкмый гына боз өстен чистартырга керешә. Аркасыннан без төртеп екканда ябышкан карлары да кагылмаган иде әле үзенең...

Кинәт кенә «Гаптери!» дип кычкырып җибәргәнемне һәм аның янына йөгереп төшеп киткәнемне абайламый да калдым.

Шалкан бурлары

Безнең урам малайларын өлкәннәр шаяртып һәм бераз үз итеп «шалкан бурлары» дип йөртәләр. Шалканны кем яратмый соң инде аны?!. Бу исемне тагуларына һич исебез китмәде. Аны йөртүебезгә ниндидер горурлык хисе дә юкмы икән әле үзебездә?! Кем дигәндә, шалкан бурлары дисәләр, минем үземнең дә күңел күтәрелеп китә. Һәрхәлдә, урамда без сигез малай булсак, сигезебез дә бу исемне күкрәк киереп йөртергә сәләтле идек.

Көннәрдән беркөнне район үзәгеннән авылыбызга яңа председатель килде. Аның безнең класста укыячак малае да бар икән. Ул гына да түгел, алар гаиләсе яңа җиткерелгән алты почмаклы колхоз фатирына — безнең урамга күченделәр. Зур кызыксыну уятты бу яңалык...

Икенче көнне көтү кугач ук өйләре каршына җыелдык, шәһәрдән килгән яңа председатель малаен тизрәк күрәсе килә иде безнең.

— Һи, персидәтел малае бу вакытта торамыни ул!..

— Шәһәр малайлары сәгать унга чаклы йоклыйлар бит алар.

Шулай сөйләшә генә башлаган идек, көтмәгәндә арабыздан берәү әче иттереп сызгырып җибәрмәсенме... Кем булсын, шул Барый инде, аның кебек сызгыручы бөтен авылында юк, беләсегез килсә.

Үзебез тиз генә Хуҗа абыйларның бура артына кереп качышып беттек. Миңлегаязның: «Малайлар, чыкты бит»,— дигән тавышын ишеткәч, тәндә кырмыскалар чабышкандай булып алды.

Капка төбендә уртача гына буйлы бер малай басып тора иде. Безне күргәч, каушамады тагы үзе, турыдантуры бура янына ук килеп тә басты.

— Малайлар, әйдә танышыйк, без сезнең урамда торачакбыз,— ди.

— Торсаңни?..— Миңлегаязның бу сүзе безгә ишетелмәде дә кебек, аның төртмәле телен, сәер гадәтен яхшы беләбез ич.

Шәһәр малае булса да, үзе болай ярыйсы гына күренә тагы... Малайлар сүзсез генә Барыйга борылдылар. Ә ул аякларын асылындырып бурага атланган да, үз дәрәҗәсен белеп, эре генә председатель малаен күзәтә.

— Малайлар, ишетмисезмени?..

— Ишетсәни?..

Ну бу Миңлегаязны, тәки үпкәләтә бит инде.

Ниһаять, Барый да сүзгә кушылды:

— Ишетмәскә, әллә син авыл малайларын колаксыз булалар дип уйлыйдырыеңмы?

Малайларга кызык булып китте. Барый кулларын чалбар кесәсенә тыккан көе генә бура өстеннән сикереп төште дә председатель малаена таба атлады. Инде нинди тамаша булыр икән дигәндәй, һәммәбез тынып калдык.

— Исемең ничек? — дип сорап куйды Барый тыныч кына.

— Фәрит.

Исеме ярыйсы икән үзе.

— Ә без «шалкан бурлары» булабыз!..

Барыбыз бертавыштан шаркылдап көлеп җибәрдек. Фәрит тә авыз читеннән генә елмаеп алды (шәһәрчә көлү шундый буладыр инде).

Күңел күтәрелеп китте, таякларга атландык та Барыйлар тыкрыгыннан инеш буена җилдерттек. Фәрит тә безгә иярде. Урам аша чыкканда ботинкасы беләи ташка абынып егылса да, тиз генә торып яңадан чапты. Йөгерешеп төшкән көйгә, күлмәк-ыштаннарны чирәмгә ыргытып, суга чумдык. Тыныч кына йөзеп йөргән казурдәкләр пырхылдашып тирә-якка качышып беттеләр, буада «бака туе» башланды.

Коенып туйгач, тиз генә чыклы үлән өстеннән киемсалымнарны эләктереп, шалкан басуына төшеп китәргә иде исәп. Көтмәгәндә председатель малае әче иттереп кычкырып җибәрде дә кия башлаган чалбарын җиргә атып бәрде. Эшнең нәрсәдә икәнен шунда ук

сизенеп алып көлешә башладык, кайсыдыр тегенең чалбар төбенә кычыткан салган икән. Ике балагыннан тотып селеккәч, чалбар эченнән бер кәҗә туярлык кычыткан төште.

Су буйлап кына, туры юлдан шалкан басуына юл тоттык. Бернәрсә дә булмаган кебек, Фәрит:

— Хәзер кая барабыз, малайлар? — дип сорап куйды.

— Шалкан басуына, кәнишне.

— Персидәтел малае безгә ияреп йөрмәс инде...

Ә Фәрит бу сүзләрне, әйтерсең, ишетмәде дә, тузан кунып өлгергән ботинкаларын ике кулына тоткан көе ул тын гына безнең арттан атлый иде. Күңеле артык төшенке күренми үзенең, әллә сер бирмәгән булуы гына. Шулай да әле бер сәгать чамасы гына элек каплкадан килеп чыккан председатель малае түгел иде инде ул. Ничектер үзгәргән һәм шул ук вакытта үз булып та киткән...

Шул вакыт бер дә көтмәгәндә Миңлегаяз җәһәт кенә Фәритнең башындагы фуражканы эләктереп алды да:

— Малайлар, карагыз, күгәрчен очыртам! — дип, яр буенда үсеп утырган ялгыз каен башына ыргытты. Каен тузыдай ак фуражка тиен кебек җитез генә бер ботактан икенче ботакка сикерде дә яшел яфраклар эченә кереп юкка чыкты. Карашлар Миңлегаязга төбәлде. Аның бу кыланышын хуплаучы булмады. Шуны аңлагандай, ул үзалдына: «Очыртсани?..»— дип куйды.

Фәритнең тәмам ачуы чыкты, күрәсең, көтмәгәндә ботинкаларын вак ташлар өстенә атып бәрде дә Миңлегаязның үзен суга төртеп төшерде. Шунда гына без бертавыштан көлеп җибәрдек. Судан чыккан этәч сыман Миңлегаяз кулларын бутый-бутый Фәриткә ташланды. Фәрит, киресенчә, аз.гына да исе китми тик басып тора. Миңлегаяз, бу тынлыкны күреп, бераз сагая, шүрли төште. Аның тәненә ябышкан ыштаныннан, күлмәк җиңнәреннән шыбырдап су ага иде...

— Малайлар,— диде ул, тагын бер адым якынрак килеп,— сез нәрсә карап торасыз! — Һәм, яңадан Фәриткә борылып:— Беләсеңме безнең урамда моның өчен нишләтәләр? — дип, этәчләнүен дәвам итте.— Бу сиңа

шәһәр түгел, тешләреңне кесәңә җыеп кайтып китәсең киләме әллә?..

Фәрит, аны үртәгәндәй, көлемсерәп кенә: «Шуннан?..» — дип куйды. Тагын көлешеп алдык. Беребез дә Миңлегаязга ярдәмгә килергә җыенмый иде. Үпкәләгән сыман ул Барыйга карап куйды. Барый, көлүеннән туктап: «Җитте, бар алып төш!» — дип агач башына күрсәткәч, без бөтенләй гаҗәпләнеп калдык. «Нужәли алып төшәр икән?!» Барый әйткәч, алып төшми дә булмас шул. Миңлегаяз артык карышып тормады, песи кебек җиңел генә каен башына менеп тә китте.

...Көн тагы да яктырыбрак, матураебрак киткәндәй булды. Әрәмәлекләргә сыенып аккан инеш бөтенләй тынып калган диярсең. Вак таш сибелгән сөзәк яр читләтеп юлыбызны дәвам иттек.

Ләкин ак балчыклы ярны үткәч, түбән оч малайларының су коена торган җире — иске тегермән буасы янында яңадан тукталырга мәҗбүр булдык. Гадәттә без бу төшне бакча артлап кына үтеп китә идек. Безне күреп тә алдылар:

— Малайлар, әнә «шалкан бурлары» төшеп килә,— дип кычкырды берәү. Бу — түбән оч малайларының башлыгы Рафаэль тавышы иде.

— Булсани, үзегезне белегез!

Миңлегаяз да җавапсыз калмады.

Алар яңадан су өстендә юка таш сикертеп уйнауларын дәвам иттеләр.

— Минеке дүрт тапкыр сикерде,— дип кычкырды Хөсәен дигән малайлары.

— Валлаһи диең...

— Әйе инде, ышанмасаң, әнә Наилдән сора, ул да күрде. Иеме, малай?

Шуңа да исләре китеп сөйләшеп торалар инде, безнең урам малайларының теләсә кайсы сикертә алай гына. Барый кулына бер юка гына таш алып очыртып җибәргән иде, ул ыргыткан таш су өстендә бер-бер артлы биш боҗра ясап юкка чыкты. Хөсәен дә, уздырырга теләп, Наил кулындагы юка ташны алып ыргытып җибәрде. Таш яр буеннан сикергән бака кебек су астына керде дә югалды.

Безнең урам малайлары: «Һи-и, Хөсәеннең болай булгач бер генә хатыны була инде»,— дип көлешә башладылар. Хөсәеннең әрекмән яфрагы кебек олы колаклары шунда ук кызарып чыкты. Наил дә, яңа гына кулына алган әйбәт ташын кире җиргә атып, бераз артка чигенде.

Рафаэль генә, сер бирмәгән булып:

— Соң, сезнең бар белгәнегез таш сикертү белән шалкан урлау гына бит,— дип әйтеп куйды.

— Таш сикертү белән шалкан урлау гына дигән була, үзегез нишли беләсез соң сез?

— Шалкан урламыйбыз, кәнишне...

— Урласани?.. Сезнең кулдан ул да килми бит әле.

Моңа кадәр бер читтә шыпырт кына басып торган Пәтих Зәкиенең дә теле бар икән:

— Соң сез футбол да уйный белмисез бит,— ди, авызын ерып.

Беразга сүзсез калып, җавап көткәндәй, Барыйга карап куйдык. Чынлап та, футбол дигәндә мактанырлык түгел иде безнең. Нишләргә икән?..

Безнең өчен Фәрит җавап бирде:

— Нигә уйнамаска. Уйныйбыз аны, шулай бит, малайлар?

Барый да, озак көттермичә:

— Кәнишне! — дип өстәп куйды.

— Әйдәгез хәзер үк уйныйбыз!

...Түбән оч малайлары, шунда ук әзерләнә дә башлап, Наилне авылга тупка йөгерттеләр. Без дә Барыйны урап алып сөйләшә башладык.

— Безнең команданың исеме «Метеор», сезнеке ничек? — ди Рафаэль.

Безнең әле команда да, аның исеме дә юк иде, әлбәттә. Уйлана торгач, көлешә-көлешә, бертавыштан командабызны «Шалкан бурлары» дип исемләргә булдык.

Ул арада бер кулына футбол тубы, икенче кулына ниндидер сумка тотып Наил да төшеп җитте. Түбән очлар шул сумкадан барысы да бер төрле майкалар алып кия башлагач, шүрләп тә куйдык. Майкаларының күкрәк турысында «Метеор» дип язылган иде. Без

дә барыбыз бер үк төрле «формада» калып — күлмәкләрне салып — футбол кырының уртасына чыгып бастык.

Уен башланды. Капкага Миңлегаяз басты. Түбән очлар, тупны бер-беренә оста гына биреп, безнең капканы штурмлый башладылар. Аяк чалсак та, читкәрәк тибеп очырсак та, туп барыбер аларда кала. Ул арада Хөсәен типкән туп Миңлегаязның аяклары арасыннан безнең капкага кереп тә китте. Чирәм ашап йөргән казларны куркытып, Миңлегаяз сукрана-сукрана туп артыннан йөгерде.

Озак та үтмәде, очып килгән тупны Рафаэль җиңел генә эләктереп алып яңадан башы белән безнең капкага юнәлтте. Эшләр харап бит болай булгач, урамга чыгарлыгыбызны да калдырмыйлар...

Уен тагы футбол кырының уртасыннан башланды. Бу юлы Барый тупны турыдан-туры Фәриткә җибәрде. Аның тәне безнекеннән аграк булып, барыбыздан да аерылып тора иде. Фәрит «Метеор»ның бер-ике малаен узды да, тупны Барыйга калдырып, үзе алга йөгерде. Барый тупны шунда ук кире Фәриткә таба юнәлтте.

Кемдер:

— Менә ичмасам бу гол! — дип кычкырып җибәрде. Фәрит типкән туп түбән очлар капкасының өске почмагына выжылдап кереп китте.

Уен һаман кыза барды. Миңлегаяз да инде капкага таба килгән тупларны берәм-берәм тота бара иде.

Хөсәен, уен бетәргә бер генә минут калды дип, сәгатенә карап торган арада, берничә малайны җиңел генә узып, Фәрит тагын бер «гол» кертеп куйды.

...Исәп 2 гә 2 генә булса да, безнең күңелләр гадәттән тыш күтәренке иде. Күлмәкләрне иң өсләренә салып, үзебезнең урамга таба менеп киттек. Миңлегаяз белән Фәрит кенә бераз арттарак калып, кызып-кызып үзара нидер сөйләшәләр иде.

ЭЧТӘЛЕК

Яңа елга күчтәнәч . . . 3

Куркак Гаяз 4

Зәңгәр бантик 6

Урак өсте иде 9

Актүшем 12

Зәлифә 16

Хоккей, без һәм Гаптери . . 21

Шалкан бурлары 25

Ринат Сафиевич Мухаммадиев

ПОДАРОК НА НОВЫЙ ГОД

(на татарском языке)

Рецензентлары Нур Гыйззәтуллин, Габделхәй Сабитов
Редакторы Резеда Вәлиева.
Художество редакторы Л. С. Ибраһимова
Техник редакторы А. С. Исхакова
Корректоры С. С. Мөхәммәдьярова

ИБ № 1470.

Наборга бирелде 5/II-79 ел. Басарга кул куелды 24/V-79 ел. ПФ 03041. Типография кәгазе № 1. 60×90[1]/[16]. Учет.-изд. табагы 1,59. Басма табагы 2,0. Заказ А-93. Тираж 10 000. Бәясе 5 тиен.

Татарстан китап нәшрияты.
Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство.
Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

5 тиен